КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 11 июль г.Казань № 573

Транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрне каплау өлешендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрне каплау өлешендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 11 июль, 573 нче
карары белән расланды

Транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрне каплау өлешендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт оешмаларына алып бетерелмәгән керемнәрне каплау өлешендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансферт бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрен сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр була:

транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыручы транспорт оешмалары белән җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында шартнамәләр булу;

законнар нигезендә билгеләнгән муниципаль маршрутлар буенча транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән җайга салына торган тарифлар буенча гамәлгә ашырыла торган пассажирлар йөртелгән һәм багаж ташылган булу;

бәяләрне (тарифлар) дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте вәкаләтле органының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән гамәлгә ашырыла торган пассажирлар йөртү һәм багаж ташу хезмәте күрсәтүгә тарифларны билгели торган норматив хокукый акты булу;

соңгы 3 елда транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән җайга салына торган тарифлар буенча хезмәт күрсәтелә торган муниципаль маршрутларның озынлыгын кимендә 2 километрга арттыру.

5. Башка бюджетара трансферт Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына түбәндәге шартларда бирелә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендәге җирле үзидарә органының финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль хокукый акты булу;

җирле бюджетта (җирле бюджетның җыелма бюджет исемлегендә) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү өчен аларны үтәүгә кирәкле күләмдә (Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелүгә планлаштырыла торган башка бюджетара трансферт күләмен кертеп) бюджет ассигнованиеләре булу;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге йөкләмәсен күздә тота торган Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансферт бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү һәм әлеге килешү белән күздә тотылган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык.

6. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертлар бүленеше Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

7. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткече (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) булып «транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән даими йөртүләр маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты» күрсәткече ярдәмендә бәяләнә торган транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда транспорт хезмәте күрсәтүнең ышанычлылыгы тора, аның мәгънәсе ≥ 0,96 була.

Хисап чорында транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән даими йөртүләр маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты ($К_{расп}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К_{расп} = \frac{Q_{рейсрасп}}{Q_{рейс}} \geq 0{,}96 ,$$

монда:

$Q_{рейсрасп}$ – хисап чорында транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда расписаниедә билгеләнгән вакыт эчендә яки хәрәкәт расписаниесеннән рөхсәт ителгән тайпылышлар чикләрендә башкарылган рейслар саны;

$Q_{рейс}$ – хисап чорында транспортның шәһәр җир өсте электр һәм (яки) урамнан тыш төрләре белән пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашырганда рейсларның гомуми саны.

Нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәләренә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 17 нче пунктында күрсәтелгән, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре тапшырган хисаплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

8. Башка бюджетара трансфертны алу өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

башка бюджетара трансфертка ихтыяҗны финанс-икътисадый нигезләү белән ирекле формада язылган башка бюджетара трансферт бирү турында заявка (алга таба – заявка);

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең вәкиллекле органы карарыннан вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында өземтә;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендәге җирле үзидарә органының финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль хокукый акты;

беренчел статистика мәгълүматларын бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат (Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге исеменнән беренчел статистика мәгълүматларын бирергә вәкаләтле зат) тарафыннан имзаланган «Шәһәр электр транспорты турында мәгълүматлар» формасы буенча мәгълүматлар.

9. Министрлык:

заявканы кергән көнендә теркәүгә ала;

теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансферт бирү турында яки башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

тапшырылган документларның, алардагы мәгълүматларның бу Тәртип белән каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмавы.

Башка бюджетара трансферт бирүдән баш тартылган очракта, Министрлык карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә бу турыда Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегенә хәбәрнамә җибәрә.

11. Башка бюджетара трансферт Министрлыкның башка бюджетара трансферт бирү турындагы карары кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә төзелгән килешү нигезендә бирелә.

12. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертның күләме;

нәтиҗәлелек күрсәткеченең мәгънәсе;

башка бюджетара трансфертны күчерү тәртибе һәм вакытлары;

башка бюджетара трансферттан файдалану һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченә ирешү турында хисаплылык бирү вакытлары һәм формалары;

бюджетара башка трансфертны алучы тарафыннан нәтиҗәлелек күрсәткеченең билгеләнгән мәгънәсенә ирешелмәү нәтиҗәләре;

килешүдә каралган башка бюджетара трансферт алу йөкләмәләренең Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

13. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансферт күләме (С) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$С = \Sigma С_{ij},$$

монда:

$С_{ij}$ – шәһәр җир өсте электр транспортының һәм урамнан тыш транспортның i төре буенча Татарстан Республикасының j муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансферт күләме;

$$С_{ij} = З_{ij} – Д_{ij} \le ЛБО,$$

монда:

$З_{ij}$ – Татарстан Республикасының j муниципаль берәмлегендә шәһәр җир өсте электр транспортының һәм урамнан тыш транспортның i төре белән җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру чыгымнары, мең сум;

$Д_{ij}$ – Татарстан Республикасының j муниципаль берәмлегендә шәһәр җир өсте электр транспортының һәм урамнан тыш транспортның i төрендә йөргән өчен түләүдән алынган керемнәр, мең сум;

ЛБО – бу Тәртипнең 3 нче пунктында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары.

14. Министрлык башка бюджетара трансферт бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә килешү проектын Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегенә имза куюга җибәрә.

15. Килешү Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегеннән имза куелган килешү алынган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә Министрлык тарафыннан имзалана.

16. Башка бюджетара трансферт Министрлык тарафыннан килешүгә Министрлык кул куйган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә Федераль казначылыкның территориаль органына ачылган шәхси счетка Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына күчерелә.

17. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге килешүдә каралган формалар, вакытлар һәм тәртип нигезендә башка бюджетара трансферттан файдалану

турында һәм нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәсенә ирешү турында Министрлыкка хисаплар тапшырырга тиеш.

18. Башка бюджетара трансферттан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәсен һәм план елын төгәлләү йомгаклары буенча фактта ирешелгән нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәсен чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

19. Әгәр дә башка бюджетара трансферт бирү елның 31 декабре хәленә карата муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган нәтиҗәлелек күрсәткеченең мәгънәсенә ирешү буенча йөкләмәләр бозылса, башка бюджетара трансферт муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансферт бирү елыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр тулы күләмдә кире кайтарылырга тиеш.

20. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бирелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

21. Бу Тәртип нигезендә алынган, агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты keremенә кире кайтарылырга тиеш.

Бу Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, әлеге акча Татарстан Республикасы бюджеты керемендә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләтелергә тиеш.

22. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

23. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан башка бюджетара трансферт максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән акча Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнары белән каралган мәҗбүри түләтү чаралары кулланыла.

24. Башка бюджетара трансфертларны максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.